РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«7» февраль 2025г. г. Альметьевск № 339

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданы турында Нигезләмә хакында» 2022 елның 28 декабрендәге 192 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә, 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү кысаларында

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданы турында Нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 28 декабрендәге 192 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга кушымтаның 1 бүлегендә:

а) 1.1. пунктын «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә яшәүче 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучыларга» сүзләрен өстәргә;

б) 1.4 пунктның беренче җөмләсенә «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә яшәүче 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучыларга карата сан ягыннан чикләү кулланылмый» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хамадьяров Р.Р.).

Муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Е. Әфләтунова

СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА